| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 10.12.2025 | г. Казань | № 493-100/тэ-2025 |

«Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, Зәй шәһәренең җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларына бирелә торган җылылык китерү матдәсенә Татарстан Республикасы Тарифлар җәмгыяте дәүләт комитетының 15.12.2023 ел, №738-94/тэ-2023 карары белән билгеләнгән тарифларга 2026 ел өчен төзәтмә кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 10.12.2025 ел, №31-ПР беркетмәсе нигезендә һәм 2026 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2026 елга җылылык китерү матдәсенә тарифларны төгәлләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, Зәй шәһәренең җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларына бирелә торган җылылык китерү матдәсенә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, Зәй шәһәренең җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларына бирелә торган җылылык китерү матдәсенә 2024-2028 елларга тарифлар билгеләү турында» 15.12.2023 ел, №738-94/тэ-2023 карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча

дәүләт комитетының 11.12.2024 ел, №368-13/тэ-2024 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән билгеләнгән тарифларга 2026 ел өчен үзгәреш кертеп, 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымтада) бирергә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында төгәлләштерелгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2023 ел, № 738-94/тэ-2023
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
10.12.2025 № 493-100/тэ-2025
карары редакциясендә)

## «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, Зәй шәһәренең җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларына бирелә торган җылылык китерү матдәсенә 2024-2028 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Җайга салынулы оешманың исеме | Тариф төре | Ел | Җылылык китерү матдәсе төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Су | Пар |
| 1 | Кулланучыларга җибәрелә торган җылылык чыганагы матдәсенә тариф | | | | |
| 1.1 | «Татэнерго» АҖ | | | | |
| 1.1.1 | «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлеге | бер ставкалы, сум/куб.м | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 23,43 | - |
| | | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 26,59 | - |
| | | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 26,59 | - |
| | | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 30,61 | - |
| | | | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 30,61 | - |
| | | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 34,80 | - |
| | | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 28,81 | - |
| | | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 | 29,97 | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | кадәр | | |
| | | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 29,97 | - |
| | | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 31,17 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге